РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.11.2017 № 1422-п

«2017 елның 1 сентябреннән 2017 елның 31 декабренә кадәр өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын ашатуны тәэмин итү турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 19 сентябрендәге 1211-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү максатларында, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә , Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 1 сентябреннән 2017 елның 31 декабренә кадәр «Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ буларак тукландыруны тәэмин итү турында» 2017 елның 19 сентябрендәге 1211-п номерлы карары белән расланган 2017 елның 1 сентябреннән 2017 елның 31 декабренә кадәр өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ булган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Әлеге Нигезләмә күпбалалы гаиләләргә, 1 - 11 сыйныф укучылары өчен, кайнар туклануны түләүсез оештыру рәвешендә, социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен билгели, аларда 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләнергә һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар булуы зарур.»;

1.2. 3.1 пунктында икенче - бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия:

– әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә сыйныф җитәкчеләреннән

укучыга социаль ярдәм чараларын бирү турында гариза кабул итә;

– ата-анадан (законлы вәкилдән) баланың ОВЗ статусы белән ПМПК коллегиаль бәяләмәсе булуы турында мәгълүмат соратып ала;

– ата-аналар тарафыннан тапшырылган социаль ярдәм чараларын алучылар турындагы мәгълүматны карый һәм тикшерә һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында йә социаль ярдәм чараларын бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

– һәр айның исемлеген раслый;».

2. Әлеге карар 2017 елның 7 ноябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. 4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы И.Ф. Шакировка йөкләргә.

Саба муниципаль районының
Башкарма комитеты
Җитәкче Р.М. Гасимов